**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль районы**
**Күгәрчен авыл җирлеге Советы**

**К А Р А Р № I**

Күгәрчен авылы 2022 елның 25 марты

Җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 маддәсендәге 3 пункты нигезендә Күгәрчен авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Җир салымы һәм физик затлар мөлкәтенә салым, бу салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча недоимканы түләттерүгә өметсез дип тануның түбәндәге очракта өстәмә нигезләрен билгеләргә:

варислар мираска хокуктан баш тарткан очракта, варислар булмау яки мирас малы ачылганнан соң бер ел эчендә мирас алынмау очрагында вафат булган яисә үлгән дип игълан ителгән физик затларның недоимкасы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычы булу.

2. Җир салымы һәм физик затлар мөлкәтенә салым буенча недоимканы түләттерүгә, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслаучы документлар булып тора:

физик затның яшәү урыны буенча салым органының недоимка һәм пенялар һәм штрафлар буенча бурычлар турында белешмәсе;

физик затларның гражданлык хәле актларын теркәүне гамәлгә ашыручы орган тарафыннан физик затның үлеме фактын теркәү турында белешмәләр;

мирас хокукы турында таныклык бирү хакында белешмәләрнең булмавы турында салым органы белешмәсе.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка игълан ителгәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында: Күгәрчен авылы, Зәитовлар урамы, 1А йорт, һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан

Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күгәрчен авыл җирлеге Башлыгы А.Т.Сафин